МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 202/о

ПРИКАЗ　　　　　　　　　　　　　　　　БОЕРЫК

«28» 11 2016

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының норматив-хокукый актларына һәм норматив-хокукый актларының проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында

2009 елның 17 июлендәге «Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» № 172-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге «Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» № 96 карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге «Аерым норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» № 883 карары нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының норматив-хокукый актларына һәм норматив-хокукый актларының проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен расларга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Рәсми порталында Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Бу Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары А.М.Фроловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр　　　　　　　　　　　　　　　　И.Ә.Фәйзуллин

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының 2016 елның
«28» 11 №202/о
боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының норматив-хокукый актларына һәм норматив-хокукый актларының проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының норматив-хокукый актларына (алга таба – актлар) һәм норматив-хокукый актларының проектларына (алга таба – актларның проектлары) коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының (алга таба – Министрлык) норматив-хокукый актларына һәм норматив-хокукый актларының проектларына, Министрлыкның актларына һәм актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны да кертеп, коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза аларның хокукый экспертизасы үткәрелгәндә үткәрелә.

Актларга коррупциягә каршы экспертиза аларның кулланылышын мониторинглаганда, шулай ук Министрлыкка Министрлыкның хокукый актларында коррупциячел факторлар булу турында мәгълүмат ирешкән очракта үткәрелә.

1.3. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза дәүләт серен яисә конфиденциаль характердагы белешмәләрне тәшкил итүче белешмәләрне үз эченә алган актларга, актларның проектларына карата үткәрелми.

1.4. Коррупциягә каршы экспертиза көчен югалткан яки гамәлдән чыгарылган норматив-хокукый актларга карата үткәрелми.

1.5. Министрлыкта актларга һәм актларның проектларына коррупциягә каршы экспертизаны оештыруда төп принциплар булып түбәндәгеләр тора:

а) актларның проектларына карата коррупциягә каршы экспертиза үткәрелүнең мәҗбүрилеге;

б) актны башка норматив-хокукый актлар белән үзара бәйләнештә бәяләү;

в) актларның һәм актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы нәтиҗәләренең нигезле, объектив булуы һәм тикшерелүе;

г) актларга һәм актларның проектларына карата коррупциягә каршы экспертизаны үткәрүче затларның вәкаләтле булуы;

д) актларга һәм актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәргәндә Министрлыкның, шулай ук аның вазифаи затларының гражданлык җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлек итүе.

## 2. Актларга һәм актларның проектларына карата коррупциягә каршы экспертиза

2.1. Коррупциягә каршы экспертиза Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасына таянып үткәрелә.

2.2. Актларга һәм актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза юридик бүлекнең Министрлык тарафыннан эшләнә торган норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы булган, Министрлык боерыгы белән билгеләнгән вазифаи заты (алга таба – җаваплы зат) тарафыннан үткәрелә.

2.3. Юридик бүлеккә килеп ирешкән актларның проектлары Коррупциягә каршы экспертизага килгән норматив-хокукый актларны һәм норматив-хокукый актларның проектларын исәпкә алу дәфтәрендә (алга таба – Дәфтәр) (1 кушымта) килгән көнендә теркәлә.

Җаваплы зат Министрлык актларында аларның кулланылышына мониторинг үткәргәндә коррупциячел факторларны ачыклаганда, шулай ук актларда коррупциячел факторлар булу турында мәгълүмат алган очракта, актлар Дәфтәрдә коррупциячел факторларны ачыклаган яки тиешле мәгълүматларны алган көнне теркәлә.

2.4. Коррупциягә каршы экспертиза акт проекты Дәфтәрдә теркәлгән көннән соң биш эш көне дәвамында үткәрелә.

2.5. Актның һәм акт проектының коррупциягә каршы экспертизасы нәтиҗәләре буенча җаваплы зат тарафыннан бәяләмә әзерләнә һәм имзалана.

2.6. Актта һәм акт проектында коррупциячел факторлар ачыкланганда коррупциячел факторлар булу турында бәяләмәдә (2 кушымта) коррупциячел факторлар күрсәтелә һәм аларны юкка чыгару ысуллары тәкъдим ителә.

2.7. Актны эшләгән структур бүлекчә өч эш көне дәвамында, ачыкланган коррупциячел факторларны юкка чыгару максатында, Министрлыкның үзгәрешләр кертү турында акт проектын яисә актны көчен югалткан дип тану турында проектын әзерли һәм юридик бүлеккә коррупциягә каршы экспертизага җибәрә.

Акт проектын эшләгән структур бүлекчә өч эш көне эчендә акт проектын эшләп бетерергә һәм аны яңадан коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен юридик бүлеккә җибәрергә бурычлы. Яңадан коррупциягә каршы экспертиза өч эш көне эчендә үткәрелә.

2.8. Актларда һәм актларның проектларында коррупциячел факторлар булмаган очракта, коррупциячел факторларның булмавы турында бәяләмә (3 кушымта) ясала, ул эшләүчегә җибәрелә.

2.9. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре Дәфтәрдә теркәлә.

2.10. Министр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган тәртиптә актны (акт проектын) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына коррупциягә каршы экспертизага җибәрергә хокуклы.

## 3. Актларга һәм актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү

3.1. Министрлык тарафыннан эшләнгән һәм Министрлыкның "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге www.minstroy.tatarstan.ru рәсми сайтында (алга таба – сайт) урнаштырылган, рәсми рәвештә бастырып чыгарылган

Министрлык актлары һәм актлары проектлары коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып тора.

3.2. Министрлыкның актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен Министрлыкның акт проектын әзерләү буенча җаваплы булган структур бүлекчәсе акт проектын карап тикшерү өчен юридик бүлеккә җибәргән көнгә туры килә торган эш көне дәвамында акт проектын массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына җибәрә.

Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы, эксперт бәяләмәләрен җибәрү өчен адресны (шул исәптән, электрон почта адресын), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлау даталарын күрсәтеп, акт проектын сайтта урнаштыра.

3.3. Сайтта урнаштырылган актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү вакыты кимендә биш эш көне тәшкил итә.

3.4. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә тәкъдим характерына ия һәм Министрлык тарафыннан зарури карап тикшерелергә тиеш. Бәяләмәне алган көннән соң 15 көнлек чорда Министрлыкның структур бүлекчәсе килгән бәяләмәне карый һәм коррупциягә каршы бәйсез экспертизаны үткәргән юридик яки физик затка, бәяләмәдә ачыкланган коррупциячел факторларны юкка чыгару ысулы турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш, нигезле җавап җибәрә.

3.5. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргәндә ачыкланган коррупциячел факторлар Министрлыкның актны (акт проектын) әзерләү буенча җаваплы булган структур бүлекчәсе тарафыннан шушы Тәртипнең 3.4 пунктында билгеләнгән вакыт эчендә юкка чыгарыла.

3.6. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән кисәтүләрне юкка чыгаргач һәм тәкъдимнәрне исәпкә алганнан соң, Министрлыкның акт проектын әзерләү буенча җаваплы булган структур бүлекчәсе акт проектын, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча килгән бәяләмәләрне теркәп, яңадан карап тикшерү өчен юридик бүлеккә тапшыра. Яңадан карап тикшерү өч эш көне дәвамында башкарыла.

3.7. Әгәр дә актта коррупциячел факторлар ачыкланса, Министрлыкның шушы актны әзерләгән структур бүлекчәсе бәяләмә Министрлыкта теркәлгән көннән башлап өч көнлек чорда актка үзгәрешләр кертү буенча яки аны көчен югалткан дип тану турында чаралар күрә.

3.8. Министрлык Министрлыкның актларында һәм Министрлык тарафыннан эшләнгән актларның проектларында коррупциячел факторлар булу турында таныклый торган коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән риза булмаган очракта, Министрлык законнарда билгеләнгән тәртиптә аталган актларны (актларның проектларын), коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсен һәм үзенең ризасызлыгын нигезләгән аңлатма язуын теркәп, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына коррупциягә каршы экспертизага җибәрә.

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының норматив-хокукый актларына һәм норматив-хокукый актларының проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә карата 1 кушымта

Коррупциягә каршы экспертизага килгән норматив-хокукый актларны һәм норматив-хокукый актларның проектларын исәпкә алу дәфтәре

| № п/п | Актны (акт проектын) экспертизага кабул итеп алу датасы | Актны (акт проектын) эшләгән структур бүлекчәнең аталышы | Актның (акт проектының) аталышы | Экспертизаны үткәрү вакыты | Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәсе | Бәяләмә датасы һәм номеры |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының норматив-
хокукый актларына һәм
норматив-хокукый актларының
проектларына коррупциягә
каршы экспертиза үткәрү
тәртибенә карата 2 кушымта

**Коррупциячел факторлар булу турында бәяләмә**
**№____ ________________**

______________________________________________________________________
(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан

______________________________________________________________________
(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)
коррупциячел факторларны ачыклау һәм алга таба аларны юкка чыгару максатында, 2009 елның 17 июлендәге «Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» № 172-ФЗ Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге «Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» № 96 карары белән расланган Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы нигезендә коррупциягә каршы экспертиза үткәрелде.

Тапшырылган

______________________________________________________________________
(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)
коррупциячел факторлар ачыкланды

______________________________________________________________________
(коррупциячел факторларның төрләре күрсәтелә)

Ачыкланган коррупциячел факторларны юкка чыгару максатларында түбәндәгеләр тәкъдим ителә:_______________________________________________
(коррупциячел факторларны юкка чыгару ысулы күрсәтелә)

| | | | |
|---|---|---|---|
| ______________________ | ____________ | ____________________ | ____________ |
| (вазифа аталышы) | (имза) | (инициаллар, фамилия) | (дата) |

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының норматив-
хокукый актларына һәм
норматив-хокукый актларының
проектларына коррупциягә
каршы экспертиза үткәрү
тәртибенә карата 3 кушымта

**Коррупциячел факторлар булмавы турында бәяләмә**
**№____ ________________**

________________________________________________________________
(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан
________________________________________________________________
(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)
коррупциячел факторларны ачыклау һәм алга таба аларны юкка чыгару максатында, 2009 елның 17 июлендәге «Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» № 172-ФЗ Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге «Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» № 96 карары белән расланган Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы нигезендә коррупциягә каршы экспертиза үткәрелде.

Тапшырылган
________________________________________________________________
(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)
коррупциячел факторлар ачыкланмады.

| ________________________ | ____________ | ________________ | ____________ |
|---|---|---|---|
| (вазифа аталышы) | (имза) | (инициаллар, фамилия) | (дата) |